СОВЕТ СОБОЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ СОБОЛЕВСКИЙАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.09.2018 с.Соболевское № 58-238

## Соболевский авыл җирлеге территориясендә гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 28.07.2004 № 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 пункты, Соболевский авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Соболевский авыл җирлеге Советының 20.09.2018 ел № 57-235 карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 20.09.2018 ел № 54 номерлы Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Соболевский авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2019 елда Соболевский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юллау белән риза булырсызмы:

- Соболевский авыл җирлегенең торак пунктларында зират коймаларын ремонтлау

ӘЙЕ ЮК.

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О. Н. Майорова